**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАРАГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

«13» нче ноябрь 2019 ел №212

Олы Карагуҗа авыл җирлеге Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” гы 2014 елның 164 номерлы карарына (Олы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 июненнән 201 номерлы, 2015 елның 14 нояберennән 11 номерлы, 2018 елның 16 ноябереннән 166 номерлы үзгәрешләр кертелгән карарлары белән) үгәрешләр кертү

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 29 сентябрендәге 321-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Карагуҗа авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Олы Карагуҗа авыл җирлеге Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” гы 2014 елның 164 номерлы карарына (Олы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 июненнән 201 номерлы, 2015 елның 14 ноябереннән 11 номерлы, 2018 елның 16 ноябереннән 166 номерлы үзгәрешләр кертелгән карарлары белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 1 пунктчасының өченче абзацындагы "бирелгән” һәм "дачный” дигән сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокук порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Яшел Үзән муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Олы Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Олы Карагуҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт (мәдәният йорты бинасы), Олы Күлбаш авылы, Тау асты урамы, 26 йорт (мәдәният йорты бинасы).

4. Карар салым законнары нигезендә үз көченә керә.

**Олы Карагуҗа авыл җирлеге**
**Башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.Р. Минһаҗев**